РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТУМУТУКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Тельмана, д.62Б, с.Тумутук,
423316

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТЫМЫТЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тельман ур., 62 Б нче йорт,
Тымытык авылы, 423316

Тел./факс(885592)34-3-42;E-mail:Tumut.Azn@tatar.ru;https://aznakayevo.tatarstan.ru/tumutukskoe-selskoe-poselenie.htm


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«13» ноябрь 2023 ел № 24

Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылында урнашкан җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча Тымытык авыл җирлегендә яшәүчеләрнең яшәү шартлары, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре уңай шартларын үтәү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Тымытык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре, Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылында урнашкан 1000 кв.м.мәйданлы 16:02:080101:2009 кадастр номерлы булган - бакчачылык алып бару (код 13.1) - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын оештыручы итеп - Тымытык авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;

- үткәрү вакыты - 2023 елның 23 ноябреннән 2023 елның 7 декабренә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт адресы буенча урнашкан Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы.

- 2023 елның 7 декабренә кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә:Тымытык авылы, Тельмана урамы, 62Б, Азнакай муниципаль районының Тымытык авылы җирлеге Башкарма комитеты.

3. Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 7 декабренә кадәр, җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртүгә рөхсәт бирү

турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турындагы хәбәрләрне җибәрергә;

- җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында нәтиҗә әзерләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Х. Гыйләҗева